СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2026 г. Агрыз № 11-9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 28 декабрендәге 33-5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә, җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарып булмый торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә ярдәм күрсәтү очракларының Тәртипкә һәм исемлегенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 28 декабрендәге 33-5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә, җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарып булмый торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә ярдәм күрсәтү очракларының Тәртипкә һәм исемлегенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Муниципаль ярдәм алучыларның максатчан файдалануын, муниципаль ярдәмне бирү тәртибен һәм шартларын үтәүләрен тикшереп тору һәм тикшерү, шул исәптән аны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнарына йөкләнә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә һәм эшкуарлыкка ярдәм буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов